I БҮЛЕК

# Багышлаулар, поэмалар

*Туган ягым, туганнарым,*
*минем кадерлеләрем!*
*Сезнең белән бергә үтә*
*бу озын гомерләрем.*

*Хәтта бакыйга күчкәч тә*
*сезне эзләп чабармын,*
*Мин кайттым әйләнеп диеп,*
*күңелегезне кагармын!*

## ҖИРСҮ

Балкышка күмелгән чит яклар
Тартса да үзенә күңелне…
Тик аяк басуга ул җиргә,
Сагынам мин туган илемне.

Гөлләрен иснәсәм җиремнең,
Көйләрен көйләсәм илемнең,
Бәхетем ташыган шул чакта
Җиңәрмен мин хәтта үлемне.

Чит җирнең моңнары чакыра –
Бизәр күк була һәр көнемне…
Тик аяк басуга ул җиргә,
Сагынам мин милли көемне.

Аларның берсен дә тиңләмим
Болынлы, чәчкәле илемә,
Тилмереп, сагынып кайтамын
Үз милли көемә, телемә.

Гөлләрен иснәсәм җиремнең,
Көйләрен көйләсәм илемнең,
Бәхетем ташыган шул чакта
Җиңәрмен мин хәтта үлемне.

*1996, Казан*

## ЯУШИРМӘГӘ КАЙТТЫМ

Яуширмәгә янә кайттым әле,
Гомерләрем көзгә авышкач.
Күзләремне яшь пәрдәсе сарды,
Туган авылым белән кавышкач.

Яшьлегемдә аткан гөл-чәчкәләр
Кырларымны инде бизәми.
Капка төпләрендә әбекәйләр
Кайттыңмы дип кулын изәми.

Мине белгәннәрнең бик күбесе
Бер-бер артлы китеп барганнар.
Өй тутырып үскән балаларның
Тавышлары тынып калганнар.

Безгә белем биргән агач мәктәп,
Җимерелеп, җирдән сөрелгән.
Балачакның моңсу ядкәрләре
Еллар тасмасына төрелгән.

Үткәннәрне сагынып, аны сүтәм —
Хатирәләр туа тезелеп,
Һәр сәхифә искә төшкән саен,
Үзәкләрем куя өзелеп.

Авыл читендәге безнең йортның
Капка-куралары кыйшайган.
«Ташладыгыз безне» дигән кебек,
Ишек-тәрәзәләр турсайган.

Әле кайчан гына чыр-чу килеп
Тугыз бала үскән бу өйдә
Агачлары гына тибрәләләр
Әти салып киткән бер көйгә.

Кайда соң сез минем сабакташлар,
Бергә уйнап үскән күршеләр?
Гомер офыклары якыная,
Насыйп булыр микән күрешүләр?

Юксынуга түзми китеп барам,
Онытылырмын, диеп, каламда...
Булмый икән – туган Яуширмәкәй
Тарта мине үзенә һаман да.

* * *

Авылымның сихри табигате
Шифа биргән элек-электән.
Үскән анда кызның иң чибәре,
Егетләре булган сөлектәй.

*1994*

## ҮПКӘЛӘМӘ МИҢА, ТУГАН АВЫЛЫМ

Үпкәләмә миңа, туган авылым,
Ташлап киттең диеп рәнҗемә,
Унбиш яшьтән синсез яшәгәнгә
Мин үзем дә әрним, Яуширмәм.

Көн-сәгатькә кайтып китүләрдән
Истә кала бары рәшәләр;
Язмышыңда синең янар өчен
Кирәктер шул синдә яшәүләр.

Хәтерләрдә генә сакланадыр
Кыр-урманнар, Якты күлләрең,
Җиләк җыйган хәтфә яланнарың,
Йөгерешеп менгән үрләрең.

Бер кайтасы иде, озак итеп
Кырларыңны иңләп йөрергә,
Урам тутырып аваз сала-сала,
Көтү кайтуларын күрергә.

Тик нишлим соң, ерактан ук танып
Каршы алыр кешең булмагач,
Тәгәрәшеп үскән өй кырында
Гөл-чәчкәләр балкып тормагач.

Кайтып булмый икән, булмый икән,
Күпме сагынсаң да өзелеп,
Тилмерәсең икән еллар буе,
Китәр өчен сине бер күреп.

Үпкәләмә миңа, туган авылым,
Оныттың дип миңа рәнҗемә.
Онытып буламы соң үскән җирне,
Йөрәгемдә бит син, Яуширмәм.

*1996, Казан*